

Халисә Сафиулла кызы Кугушева - Темник районы Аксел урта мәктәбе директоры. Анын турында һаман мактау сvзләре ишетергә туры килә. Татарлар - нәселенә кара, аннары кем икәне билгеле булыр, диләр. Шулай дорестер инде; анын әти-әнисе дә авылларында хормәтле кешеләр. Алар белән Халисә Сафиулловна таныштырып:
- Әти-әнием Сафиулла Алим улы белән Адилә Хәнәфи кызы Акбулатовлар инде сиксән яшьлек чикне уздылар. Аларнын жилкәләрендә - озак тырыш хезмәт эшчәнлеге һәм 54 ел бергә гомер итv дәвере. Әтием зур гаиләдә туа, анда 8 бала тәрбияләнеп vсә. Башлангыч сыйныфларда гына укырга туры килә ана. Инженер гына тvгел, топ белеме дә булмый торып, авылда йортлар, фермалар този ул, тозелеш бригадасы бригадиры була. Моннан тыш, арбалар ясаучыларнын хезмәт династиясен дәвам итеп, кvп еллар колхоз ихтыяжлары очен чана һәм арбалар ясаган. Шулай ук теләк белдергән авылдашларына да. Бvгенге конгә кадәр әтиемнен vз куллары белән тозелгән якын-тирә авыллардагы һәм Акселдагы шәхси йортлар, шул исәптән 45 ел элек vз йортыбыз да орнаментларынын матурлыгы, линияләрнен тогәллеге, пропорцияләрнен дореслеге белән игътибарны жәлеп итә. Ә ин моһиме, барлык проектларны да ул vзе уйлап тапкан.

Тагы мин балачактан ук әтинен безне мәктәптә яхшы укырга чакыруын хәтерлим. Бернигә дә карамастан, ул гел намус белән эшләде; vз эше очен ана беркайчан да оят булмады. Шуна ул һәрбер кешенен кvзенә туры карап тыныч йоклый.       Әнисе турында да жылы сvзләр ишеттерде әнгәмәдәшем. Адилә Хәнәфи кызы Акбулатованын да язмышы жинелләрдән булмаган. Ул 1939нчы елда туган. Боек Ватан сугышында хәбәрсез югалган әтиен ботенләй хәтерләми. Ике олы абыйсы белән ул әтисез vсә. Гомуми белем алып, ул гомере буе гади сатучы булып эшли. Сатып алучыларга намуслы хезмәте белән авылдашларынын хормәтен яулаган. Монын турында шул факт та сойли: ул товарны чиратсыз житәкчегә тvгел, ә карт әбигә яки инвалидка сата торган булган. Бер сәгать тәнәфес вакытында Адилә апа Акбулатова  тик торырга яратмаган; балаларын карарга яки хужалык буенча нәрсә дә булса эшләргә олгергән. Әмма сатып алучылар аны беркайчан да кибетнен ябык ишек тобен таптап вакытларын әрәм итмәгәннәр, кайчан ачар дип котеп тормаганнар. Пунктуальлек - ул да анын характерындагы сыйфатларнын берсе.
Сvзен дәвам итеп, Халисә Сафиулла кызы: «Әти-әнием, педагогик белеме булмаган

килеш, безне - балаларын һәм оныкларын, хезмәт союченлек, намуслылык, пухтәлек, кешеләргә карата яхшы монәсәбәтебез белән жәмгыятькә файда китерергә тиешлегебезгә ышандыра алдылар».
Сафиулла Алим улы белән Адилә Хәнәфи кызы Акбулатовлар бvгенге конгә кадәр йорт яны участогын эшкәртәләр, мал-туарларын карап vстерәләр. Боларнын барысын да vзләре башкарып чыгарга тырышалар. Хезмәтсез тормышларынын мәгънәсе юк дип тоела аларга. Гомерләре буе бернинди эштән дә курыкмаганнар һәм хәзер дә эшсез утырмыйлар, беркайчан да башка кешеләргә конләшмиләр, vз тормышларын намус белән яшиләр. Һәм шуна алар озак яшәvчеләр рәтенә бастылар да инде, дип уйлыйм.
«Олкәннәр айлыгында барлык балалар һәм оныклар исеменнән кадерле әти-әниләребезгә сәламәтлек, кvнел корлеге һәм актив озын гомер телим. Һәр кон гаилә учагыбыз тулып торсын!» - дигән теләктә Халисә ханым Кугушева.

**Н.Хәлил**